**“ М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназиянең**

**110 еллык юбилеена әзерлек” рубрикасына**

## 2 мәктәп тарихында әдәбият - сәнгать осталары

Татар халкының Хәтере һәм Бөеклеге

2 гимназия тарихы музеенда саклану –

олы киләчәгебезнең дәлиле! Үсик, ки-

ңәйик, иң тирәндәге хәтерләр уянсын!

Рахмай Хисматуллин. 1990.

1950 - 60 нчы елларда мәктәптә татар язучылары, композиторлар, рәссамнар, артистлар еш булганар. Алга таба ул очрашулар мәктәпнең иң матур традициясенә әверелә. Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзиев, Гөлшат Зәйнәшева, Ләбибә Ихсанова, Зәки Нури, Рәшит Гәрәй, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Кутуй, Нәби Дәүли, Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Ахунов, Мәхмүт Хөсәен, Гариф Гобәй, Рафаэль Мустафин кебек өлкән язучылар да, иң яшьләре дә безнең мәктәпнең кунаклары булалар. Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключеров кебек композиторлар, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Вафира Гыйззәтуллина, Эмиль Җәләлетдинов, Җәвәһирә Сәлахова, Галина Казанцева кебек җырчылар белән очрашулар иң онытылмас җәүһәрләр була.



*Сибгат Хәким һәм Габдрахман Әпсәләмовны укучылар һәм укытучылар Чаллы пристанендә каршы ала*



*Үзәктә әдипләр С. Хәким һәм Г. Әпсәләмов*



*Онытылмас очрашу мизгелләре*

Хезмәт ветераны, РСФСР ның халык мәгарифе отличнигы Анна Ивановна Солтанова-Бустерякова ул чорларны түбәндәгечә искә ала: “Безнең мәктәп Чаллыда бердәнбер татар мәктәбе иде. Аны саклап калу өчен күп көч куярга, ... яңа алымнар кулланырга туры килде. Шулай итеп кенә балаларга үз ана телләрендә уку мөмкинлеген саклап кала алдык. Тел-әдәбият укытуда һәм тәрбия эшчәнлегендә әдипләр, композиторлар һәм җырчылар белән эзлекле очрашулар гаять йогынтылы булды. Ул очрашулар шыгрым тулы залларда зур әзерлек белән үтә, укучылар, укытучылар һәм шәһәр халкы өчен зур бәйрәм була иде. Очрашулар әдәбияттан белемнәребезне арттыра, кызыксыну уята, күңелләребезне сафландыра, рухи азык бирә иде”.




*Мәгариф ветераны Анна Ивановна  Солтанова-Бустерякова (уңда)*



*Язучылар Нәби Дәүли, Ибраһим Гази,  Галимҗан Латыйп, укытучылар  Бәһрия Камалиевна һәм Анна Ивановна*



*Җәүдәт Фәйзи һәм җырчы Флера Сөләйманова белән очрашу*



*Туфан Миңнуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Ямаш Игәнәй һәм Марсель Галиев 2 мәктәп укучылары арасында. Сулда - татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлшат Нуровна Шамматова*

“Беренче тапкыр язучылар белән аралашулар шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннән башланды. Аның һәр китабын яратып укый идек. Ул әле хәрби киемен дә салырга өлгермәгән, күп орден -медальләр кавалеры, гвардия майоры, соңыннан Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. М. Хөсәен чын мәгънәсендә милли рухлы патриот шагыйрь иде. Үзенең һәр шигырен яттан белә, хисле итеп сөйли, залны үзенә каратып тота. Очрашуга рус классларында укучы балалар да теләп килә иде. Ул беркайчан да үз вакыты белән исәпләшми. Укучыларның иҗади эшләрен дә үзе укып киңәшләрен бирә. Бик сәләтле

шагыйрь иде. Шигырьләрен “находу” яза. Без аны мәктәпнең Почетлы пионеры итеп алдык. М. Хөсәен мәктәпкә “М. Вахитов ул” җырын язып бүләк итте”.




*“Язучыларны кунакка чакырганчы, алдан зур хәзерлек эшләре алып бара идек”*





*“М. Хөсәен - чын мәгънәсендә милли рухлы патриот шагыйрь. Үзенең һәр шигырен яттан белә, хисле итеп сөйли, залны үзенә каратып тота иде”*



*М. Хөсәенне зал алкышлый*

Мәхмүт Хөсәен 1990 елда гимназиягә багышлап “Яңа кеше өчен” шигырен яза. Шигырь шул елны “Мәгариф” журналының 11 нче санында басылып чыга.

Яңа кеше өчен!

Чаллы каласының М.Вахитов исемендәге беренче татар гимназиясенә багышлыйм.
Автор.

.....Ватаныңда сине, әй Мулланур,
Рух кыйбласы иткән Чаллы бар.
Ә Чаллыда исемеңне йөрткән
Милли мәктәпнең үз даны бар.
Юлыкты ул төрле түрәләргә,
Буалмады аны торгынлык.
Ә бүген ул - милли гимназия,
Бу – барыбыз өчен горурлык. ....

Әдип мәктәпкә үзенең берничә шигырь китабын бүләк иткән. Музейда әзербәйҗан телендә дөнья күргән *“Татар әдәбияты антологиясе”* саклана. Китап 1972 нче елда Бакуда басылып чыккан. Антологиядә бик күп татар әдипләренең әсәрләре тупланган. Китап та Мәхмүт Хөсәен тарафыннан бүләк ителгән һәм анда түбәндәге шигырь юллары язылган:

Гаҗәпләнмәгез, дусларым,

Мондый дип кадер кайдан?!

Туган телендә тараткан

Татарны Азербәйҗан.

М.Хөсәен. 30 нчы январь, 1974 нче ел. Чаллы.

Танылган татар язучысы Габдрахман Әпсәләмов үзенең “ Яшел яр" романында икенче мәктәп тормышыннан кайбер моментлар кулланган. Аның мәктәп коллективына язган хатында мондый сүзләр бар: “Вакытында сезнең мәктәп миңа да илһам бирде һәм иҗатымда үзенең азмы-күпме чагылышын тапты. Кыска гына итеп әйткәндә, ул минем “Яшел ярым” булды. Авыр һәм газаплы иҗат көннәремдә күңелемнән Сезнең коллектив алдында күп мәртәбәләр башымны идем”.

Язучы 1964 нче елда басылып чыккан “Әдәбиятка гомер иярә” мәкаләсендә мәктәбебез турында: “ Күренеп тора: биредә әдәбиятны чынлап торып яраталар, өйрәтәләр, өйрәнә-

ләр,  укыйлар һәм аңлыйлар",  - дип яза.



2 гимназия илебезгә бик күп танылган шәхесләр биргән. Шуларның берсе язучы, тәнкыйтьче һәм галим Ибраһим Нуруллинның да (1923-1995) яшүсмер еллары безнең мәктәп белән бәйле. Балачак чорында аңа төрле мәктәпләрдә, шул исәптән 2 мәктәптә дә белем алырга туры килә. Ул безнең мәктәпне "Әдәбиятка фатиха биргән мәктәбем " дип атый.

1966 нчы елда халкыбыз герой - шагыйрь Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтә. Татар теле укытучылары Анна Ивановна Солтанова-Бустерякова һәм Һаҗәр Фәрдиевна Гәрәевага Казанда шагыйрьнең якыннары һәм Җәлилнең шигырьләр китабын коткарып калган белгияле Андре Тимирманс белән очрашу насыйп була.



1988 нче елның 15 нче февралендә Әминә Җәлил, кызы Чулпан, батырның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүче Рафаэль Мостафин 2 мәктәптә очрашуда булалар. Музейдагы фоторәсем һәм кунаклар бүләк иткән Шамил Рафиковның "Кайда син, Җан" китабы - гимназия фондының кадерле бер истәлеге.

1988 нче елның 15 нче февралендә Чаллы Язучылар оешмасы исеменнән Кадыйр Сибгатуллин тарафыннан бүләк ителгән "Халык бәхете өчен көрәшүчеләр" китабы да - иң кадерле истәлекләрнең берсе.

1988 нче елның 14 нче мартында гимназия тарихы музеенда Мәскәү, Казан һәм Уфа шәһәрләреннән Н. Хәсәнов, Г. Жданов, Б.Мифтахов, Х.Толымбаев кунакта була.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Солтанова Анна Ивановна, Гәрәева Һаҗәр Фәрдиевна, Җамалиева Бәһрия Камалиевна, Шамматова Гөлшат Нуровна, музыка укытучысы Сәгыйтов Зөфәр Яруллович бу очрашуларны оештыруда башлап йөриләр.

1990-1991 нче уку елында 2 мәктәп базасында гимназия ачыла. Аның беренче директоры итеп милли җанлы, әдәбият һәм сәнгатькә гашыйк Муллин Рифкать Нуруллович билгеләнә. Музейда аның “Дусларымны барлыйм” дигән китабы саклана. Туксанынчы еллардан башлап гимназия коллективы һәм әдәбият - сәнгать әһелләре арасынла элемтә тагы дә активлаша.




*Язучы Факил Сафин, гимназия директоры Рифкать Муллин һәм шагыйрь Рәшит Бәшәр укучылар арасында*

2004 нче елда ”Егет икән,әйдә егет бул!” исеме астында үткәрелгән Разил Вәлиев белән булган очрашу күңелләрдә озак сакланыр. Укучылар язучының әсәрен сәхнәләштерделәр, шигырьләрен сөйләделәр, автор сүзләренә язылган җырларны башкардылар. Чараны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нурисламова Энҗе Әзгамовна әзерләде.

Халык шагыйре Роберт Миңнуллин да мәктәптә берничә тапкыр була. Әдип гимназиядәге уңай үзгәрешләрне күреп бик шатлана. Мәктәп музеендагы “Кадерле кунаклар журналы” нда аның 2008 нче елның 25 нче апрелендә калдырган язмалары саклана.




*Укытучы Шәйхелисламова  Вәрия Ганиевна  халык шагыйре Рәзил Вәлиев сүзләренә җырларны башкара*

Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин һәм Чаллы язучылары килгән көн мәктәптә бәйрәмгә әйләнде. Укучылар язучыларга үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр. Туфан Миңнуллин гимназиядәге тәрбия эшенә югары җәя бирде Чараны тәрбия эшләре буенча директоры  Харисова Энҗе Мирзануровна әзерләде, Хамидуллина   Нурия алып барды.





*Туфан Миңнуллин гимназиягә очрашуга килгәч*

Г. Камал театры артистлары белән очрашуны *“ Театр яктылыкка, нурга илтә*” дип атадык. Чараны тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Харисов Энҗе Мирзануровна һәм укытучы Шәрифуллина Зөһәйрә Вахетдиновна оештырды. Очрашуда Шәүкәт Биктимиров, Нәҗибә Ихсанова, Хәлил Әбҗәлилов, Әсхәт Хисмәт, музыкант Фуат Әбүбәкеров һәм башка артистлар катнашты. Кунаклар очрашуга әзерлекле программа белән килгәннәр иде. Алар укучыларны актерлык серләренә генә төшендереп калмадылар, үзләре дә уйнап, җырлап, биеп күрсәттеләр. Аралашу бик җанлы һәм эчкерсез мохиттә үтте.





Гимназиядә язучыларның юбилейларын зурлап билгеләп үтү матур традициягә кергән. Роберт Миңнуллин, Рәзил Вәлиев, Айдар Хәлим, Кадыйр Сибгатуллин, Факил Сафин, Рәшит Бәшәр, Рәзинә Мөхияр, Вахит Имамов, Мансур Сафин, Рәдиф Гаташ һ.б. әдипләрнең туган көннәрен һәм иҗат кичәләрен  гимназия күләмендә билгеләп үтү матур бер бәйрәмгә әйләнде. Укучылар әдипләребез һәм сәнгать осталарыбыз турында фәнни эшләр башкаралар.






*А.Хәлимгә 60 яшь*





*Айдар Хәлимнең иҗат кичәсе. 2013 нче ел*



*Рәдиф Гаташ һәм Әлфия Ситдикова бездә кунакта. 2009 нчы ел*

Язучы Факил Сафин мәктәпкә “Икенче гимназиям” җырын бүләк итте. Музыкасын да әдип үзе язган. Күпьяклы шәхесебезгә чиксез рәхмәтлебез.





*Факил Сафин язучылар һәм укучылар арасында*








*Конкурларда җиңгән укучыларыбыз язучылар арасында. 2014 нче ел*





*Язучылар  оешмасы безне башкорт язучылары белән очраштырды. 1914 нче ел*



*Екатеринбург кунаклары музейда. Каршыда Нигъмәтуллина Хәлимә Фәрдиевна. 2013 нче ел*









*“Сабантуй” хезмәткәрләре   гимназиядә. 2014 нче ел*

Чаллыда яшәүче  күп кенә әдәбият - сәнгать әһелләренең  - Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Вахит Имамов, Илдар Хаҗи, Илгиз Закиров, Азат Хөсәенов, Равил Галиев,   Айгөл Муллагалиева, Зөләйха Минһаҗева, Хәния Фәрхинең һ.б.  ның балалары   гимназиядә белем алды һәм ала.

Факил Әмәк, Рәшит Бәшәр, Рәзинә Мөхияр һәм Илдар Хаҗи үзләре дә гимназиядә әдәбият һәм театр түгәрәкләре алып бардылар һәм укучыларның иҗади осталыкларын үстерүгә ярдәм иттеләр.

Музейда әдипләребезнең үз куллары белән язып бүләк ителгән бик күп иҗат җимешләре саклана. Шагыйрә Рәзинә Мөхияр *"Сиңа булсын җырым"* дип аталган беренче шигырьләр җыентыгын иң башлап безнең музейга бүләк иткән. Моннан соң аның бик күп шигырь китаплары дөнья күрде. Тик беренчесе – аның өчен иң кадерлесе!

2015 нче елның 4 нче декабрендә Чаллы язучылары оешмасының 35 еллыгы уңаеннан республикадан һәм шәһәребезнең үзеннән иллегә якын язучы гимназиядә булдылар. Укучылар кунакларны бик җылы каршыладылар, сәхнәләштереп, язучыларның әсәрләрен укыдылар, музейда гимназиядә булган әдәбият – сәнгать осталары турында сөйләделәр, язучылар иҗаты буенча фәнни эшләр яклыдылар, "Минем гимназиям" мәктәп газетасы эшчәнлее буенча тәҗрибә уртаклаштылар, күргәзмә оештырдылар.






“Милли мирасыбыз  сагында торучыларны гимназиябездә каршы алу  - безнең өчен зур мәртәбә!”




13 нче татар сәнгать









Музей советы әгъзалары язучылар белән


Директорлар:
1990-94 Муллин Р.Н.
1994 елдан
Йосыпова Д.Ш.




Бу музей күзәгъ бик матур тәэсир калдырды. Тарихи ...
милләт кенә озын гомерле була. Сез милләтне белем ...
барасыз, шуңа сезгә олы рәхмәт!
Набиров Гөйдулла
3 декабрь, 2015

Мондагы бүген милләтнең мәгърифәт ...
рухият байлыгы.
Изге эшләрегез өчен рәхмәт.
Ширкадә
4.12.15.

Киләчәк — Гасыр Гомәр ...
Әйе, шулай! Зур уңышлар телим.
Алмир.
Ф. Гиорхания








990-
2000
2000


Ватанында синк, әй Мулланур, рух кыйбласы иткән Чаллы бар! Ә Чаллыда
исемеңне йөрткән милли мәктәпнең үз даны бар.
1941-1945
1945-1965







Гимназия советы членнары тәрбия эшләре буенча директор урынбасары

Харисова Э.М.белән.  04.12.15.


2015 нче ел-
ӘДӘБИЯТ
ЕЛЫ




Готовимся к экзаменам
















Харисова Э.М, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.,

ТР ның Атказанган укытучысы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Декабрь, 2015 нче ел.

**Гимназия һәм әдәбият – сәнгать осталары хезмәттәшлеге” – музейда язучылар белән очрашу сценариесе 4.12.15.**

*1 укучы:* 1950 - 60 нчы елларда мәктәптә татар әдәбият -сәнгать әһелләре еш булганар. Алга таба ул очрашулар мәктәпнең иң матур традициясенә әверелә. Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзиев, Гөлшат Зәйнәшева, Ләбибә Ихсанова, Зәки Нури, Рәшит Гәрәй, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Кутуй, Нәби Дәүли, Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Ахунов, Мәхмүт Хөсәен, Гариф Гобәй, Рафаэль Мустафин кебек өлкән язучылар да, иң яшьләре дә безнең мәктәпнең кунаклары булалар. Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключеров кебек композиторлар, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Вафира Гыйззәтуллина, Эмиль Җәләлетдинов, Җәвәһирә Сәлахова, Галина Казанцева кебек җырчылар һ.б. күпләр белән очрашулар иң онытылмас җәүһәрләр була.

*2 укучы:* Хезмәт ветераны Солтанова Анна Ивановна ул чорларны түбәндәгечә искә ала: “ Безнең мәктәп Чаллыда бердәнбер татар мәктәбе иде. Аны саклап калу өчен күп көч куярга, ... яңа алымнар кулланырга туры килде. Шулай итеп кенә балаларга үз ана телләрендә уку мөмкинлеген саклап кала алдык. Тел-әдәбият укытуда һәм тәрбия эшчәнлегендә әдипләр, композиторлар һәм җырчылар белән эзлекле очрашулар гаять йогынтылы булды. Ул очрашулар шыгрым тулы залларда зур әзерлек белән үтә, укучылар, укытучылар һәм шәһәр халкы өчен зур бәйрәм була иде. Очрашулар әдәбияттан белемнәребезне арттыра, кызыксыну уята, күңел-ләребезне сафландыра, рухи азык бирә иде”.

*3 укучы: Анна Иванова истәлекләреннән:* “Беренче тапкыр язучылар белән аралашулар шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннән башланды. Аның һәр китабын яратып укый идек. Ул әле хәрби киемен дә салырга өлгермәгән, күп орден – медальләр кавалеры, гвардия майоры, соңыннан Та-тарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. “М. Хөсәен - чын мәгънәсендә милли рухлы патриот шагыйрь. Үзенең һәр шигырен яттан белә, хисле итеп сөйли, залны үзенә каратып тота иде. Ул мәктәпкә “ Мулланур Вахитов ул” җырын язып бүләк итте”.

*“ Язгы яңгыр” вокаль ансамбеле “М.Вахитов ул” җырын башкара.*

*4 укучы*: Мәхмүт Хөсәен 1990 елда гимназиягә багышлап “Яңа кеше өчен” шигырен яза. Шигырь “Мәгариф” журналының 11 нче санында басылып чыга.

Яңа кеше өчен!

Чаллы каласының М.Вахитов исемендәге беренче татар гимназиясенә багышлыйм. Автор.

Ватаныңда сине, әй Мулланур,

Рух кыйбласы иткән Чаллы бар.

Ә Чаллыда исемеңне йөрткән

Милли мәктәпнең үз даны бар.

Юлыкты ул төрле түрәләргә,

Буалмады аны торгынлык.

Ә бүген ул - милли гимназия,

Бу – барыбыз өчен горурлык.

Әдип мәктәпкә үзенең берничә шигырь китабын бүләк иткән. Музейда әзербәйҗан телендә дөнья күргән *“Татар әдәбияты антологиясе”* саклана. Китап 1972 нче елда Бакуда басылып чыккан. Антологиядә бик күп татар әдипләренең әсәрләре туп-ланган. Ул да Мәхмүт Хөсәен тарафыннан бүләк ителгән һәм китапка түбәндәге шигырь сүзләре язылган:

Гаҗәпләнмәгез, дусларым,

Мондый дип кадер кайдан?!

Туган телендә тараткан

Татарны Азербәйҗан.

М.Хөсәен. 30 нчы январь,1974 нче ел. Чаллы.

(китапны күрсәтә).

*5 укучы:* Танылган татар язучысы Габдрахман Әпсәләмов үзенең “ Яшел яр" романында икенче мәктәп тормышыннан кайбер моментлар кулланган. Аның мәк-тәп коллективына язган хатында мондый сүзләр бар: “Вакытында сезнең мәктәп миңа да илһам бирде һәм иҗатымда үзенең азмы-күпме чагылышын тапты. Кыска гына итеп әйткәндә, ул минем “Яшел ярым” булды. Авыр һәм газаплы иҗат көн-нәремдә күңелемнән Сезнең коллектив алдында күп мәртәбәләр башымны идем”. (Фото, хатны күрсәтә).

Язучы 1964 нче елда басылып чыккан “Әдәбиятка гомер иярә” мәкаләсендә мәктәбебез турында: “ Күренеп тора: биредә әдәбиятны чынлап торып яраталар, өйрәтәләр, өйрәнәләр, укыйлар һәм аңлыйлар”,- дип яза.

*6 укучы:* 2 гимназия илебезгә бик күп танылган шәхесләр биргән. Шуларның берсе язучы, тәнкыйтьче һәм галим Ибраһим Нуруллинның да ( 1923-1995) яшүсмер еллары безнең мәктәп белән бәйле. Балачак чорында аңа төрле мәктәпләрдә, шул исәптән 2 мәктәптә дә белем алырга туры килә. Ул безнең мәктәпне “Әдәбиятка фатиха биргән мәктәбем “ дип атый. (Фотоны күрсәтә).

*7 укучы:* 1966 нчы елда халкыбыз герой - шагыйрь Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтә. Татар теле укытучылары Анна Ивановна Солтанова- Бустерякова һәм Һаҗәр Фәрдиевна Гәрәевага Казанда шагыйрьнең якыннары һәм Җәлилнең шигырьләр китабын коткарып калган белгияле Андре Тимирманс белән очрашу насыйп була. Ә 1988 нче елның15 нче февралендә Әминә Җәлил, кызы Чулпан, батырның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүче Рафаэль Мостафин 2 мәктәптә очрашуда булалар. Әлеге

очрашудан фоторәсем һәм кунаклар бүләк иткән Шамил Рафиковның “*Кайда син, Җан” китабы* - фондыбызның кадерле бер истәлеге (Фотоны һәм китапны күрсәтә).

*8 укучы:* 1990-1991 нче уку елында 2 мәктәп базасында гимназия ачыла. Аның беренче директоры итеп милли җанлы, әдәбият һәм сәнгатькә гашыйк Муллин Рифкать Нуруллович билгеләнә. Музейда аның “Дусларымны барлыйм” дигән китабы саклана.

Туксанынчы еллардан башлап гимназия коллективы һәм әдәбият - сәнгать әһелләре арасынла элемтә тагы дә активлаша (Фоторәсем һәм китап күрсәтә).

*9 укучы:* 2004 нче елда ” *Егет икән,әйдә егет бул!”* исеме астында үткәрелгән Разил Вәлиев белән булган очрашу күңелләрдә озак сакланыр. Укучылар язучының әсәрен сәхнәләштерделәр, шигырьләрен сөйләделәр, автор сүзләренә язылган җырларны башкардылар. (Фотоларны күрсәтә).

*10 укучы:* Мәктәпкә Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин һәм Чаллы язучылары килгән көн бәйрәмгә өйләнде. Укучылар язучыларга үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр. Туфан Миңнуллин гимназиядәге тәрбия эшен югары бәяләде. Музейда әлеге очрашудан да фотолар һәм видеоязма бар (Фоторәсемнәрне күрсәтә).

*11 укучы:* Г. Камал театры артистлары белән очрашуны *“ Театр яктылыкка, нурга илтә*” дип атадык. Очрашуда Шәүкәт Биктимиров, Нәҗибә Ихсанова, Хәлил Әбҗәлилов, Әсхәт Хисмәт, музыкант Фоат Әбүбәкеров һәм башка артистлар катнаштылар. Кунаклар очрашуга әзерлекле программа белән килгәннәр иде. Алар укучыларны актерлык серләренә генә төшендереп калмадылар, үзләре дә уйнап, җырлап, биеп күрсәттеләр. Аралашу бик җанлы һәм эчкерсез мохиттә үтте. Музейда әлеге очрашудан фоторәсемнәр саклана (Фотоларны күрсәтә).

*12 укучы:* Гимназиядә *язучыларның юбилейлары* зурлап билгеләп үтү матур традициягә кергән. Роберт Миңнуллин, Рәзил Вәлиев, Айдар Хәлим, Кадыйр Сибгатуллин, Мансур Сафин, Рәдиф Гаташ, Факил Сафин, Рәшит Бәшәр, Рәзинә Мөхияр, Вахит Имамов, Мансур Сафин, Рәдиф Гаташ һ.б. әдипләрнең туган көннәрен гимназия күләмендә билгеләп үтү матур бер бәйрәмгә әйләнде. Укучылар әдипләребез һәм сәнгать осталарыбыз турында фәнни эшләр башкаралар. (Фоторәсемнәр: “А.Хәлимгә 60 яшь”).

*13 укучы:* Язучы Факил Сафин мәктәпкә “Икенче гимназиям” җырын бүләк итте. Музыкасын да әдип үзе язган. Күпьяклы шәхесебезгә чиксез рәхмәтлебез.

*14 укучы:* Гимназиядә Чаллыда яшәүче күп кенә әдәбият - сәнгать әһелләренең - Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Илдар Хаҗи, Вахит Имамов, Илгиз Закиров, Азат Хөсәенов, Равил Галиев, Айгөл Муллагалиева, Зөләйха Минһаҗева, Хәния Фәрхинең һ.б. ның балалары белем алды һәм ала.

*15 укучы:* Музейда әдипләребезнең үз куллары белән язып бүләк ителгән бик күп иҗат җимешләре саклана. Шагыйрә Рәзинә Мөхияр *“Сиңа булсын җырым”* дип аталган беренче

шигырьләр җыентыгын иң башлап безнең музейга бүләк иткән. Моннан соң аның бик күп шигырь китаплары дөнья күрде.Тик беренчесе – аның өчен иң кадерлесе!

Бүгенге очрашудан соң безнең фонд тагы да баер дип уйлыйбыз. Ул гимназия тарихында якты бер истәлек булып калыр. “Кадерле кунаклар китабы” на фикерләрегезне язып калдырсагыз, безнең өчен зур истәлек булыр!